Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
карары

26 март, 2020 ел № 247

2019 елда Татарстан Республикасы Питрәч районы буенча
Россия ЭЭМ (МВД) бүлегенең оператив-хезмәт эшчәнлеге йомгаклары турында

«Полиция турында» 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы Федераль законның 8 маддәсенең 3 пункты нигезендә Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Питрәч районы буенча бүлегенең 2019 елда оператив-хезмәт эшчәнлеге йомгаклары турындагы мәгълүматны тыңлап, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул иттте:**

1. Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Питрәч районы буенча бүлегенең 2019 елда оператив-хезмәт эшчәнлеге йомгаклары турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы Питрәч районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенең гражданнарның гомерен, сәламәтлеген, хокукларын һәм ирекләрен яклауга, җинаятьчелеккә каршы көрәшкә, җәмәгать тәртибен саклауга, милекне һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлегенең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген 2020 елда арттыруны активлаштырырга;

2.2. Террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту чараларын үтәү буенча барлык кирәкле чараларны күрергә;

2.3. Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты белән берлектә 2020 елның 30 апреленә кадәр түбәндәге чаралар комплексын эшләргә:

- район юлларында аварияләрне киметү;
- көнкүреш җирлегендә кылына торган авыр җинаятьләрне булдырмау;
- олылар ягыннан балигъ булмаганнарга криминаль йогынты дәрәҗәсен киметү;
- балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау максатларында эш белән тәэмин ителешен яхшырту.

2.4. Җирле үзидарә органнары, хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый оешмалар белән берлектә җәмәгать тәртибен саклауда һәм профилактик чаралар үткәрүдә катнашу буенча максатчан эшне дәвам итәргә.

3. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов